ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.12.2023 г. Казань № 473-11/тко-2023

«Буа ТКХ КҖП» (Инженерлык челтәрләре) ачык акционерлык җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 555-15/тко-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы чик тарифларга 2024 ел өчен төзәтү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя куюу турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 08.12.2023 № 53-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, 2024-2025 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик тарифларны һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керемен үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Буа ТКХ КҖП» (Инженерлык челтәрләре) ачык акционерлык җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021-2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 № 555-15/тко-2020 карарына (Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 434-23/тко-2022 карары керткән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4. «Буа ТКХ КҖП» (Инженерлык челтәрләре) ачык акционерлык җәмгыятенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 109 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары

нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 555-15/тко-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
08.12.2023 № 473-11/тко-2023
карары редакциясендә)

Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Буа ТКХ КҖП (Инженерлык челтәрләре)» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2021-2025 елларга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | 2024 ел | | 2025 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Буа муниципаль районы | | | | | | | | | |
| 1 | «Буа ТКХ КҖП (Инженерлык челтәрләре)» ачык акционерлык җәмгыяте* | | | | | | | | | |
| | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | 63,49 | 63,49 | 63,49 | 118,43 | 74,72** | - | - | - | - |
| | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/тонна | - | - | - | - | - | 576,56 | 1513,54 | 1076,20 | 1076,20 |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.
<**> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.11.2022 № 434-23/тко-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге